ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.04.2026 г. Агрыз № 44

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен һәм гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау турында» 2023 елның 15 ноябредәге 85 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Гражданның мөрәҗәгате белән бәйле рәвештә аның иминлеге гарантияләре " 4 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 4.3 пункт өстәргә:

«4.3. Оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясе иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, федераль башкарма хакимиятнең иминлек тәэмин итү өлкәсендәге органының, тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, федераль башкарма хакимиятнең дәүләт саклау өлкәсендәге органының мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында электрон документ рәвешендә мөрәҗәгатьләр җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И.Н. Халиковка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов